**Татарстан Республикасы**
**Арча муниципаль районының**
**Арча шәһәре муниципаль берәмлеге**
**Арча шәһәр Советы**
**422000, Арча ш. Совет мәйданы, 27**
**тел. 3-16-25, 3-12-35**

**Татарстан Республикасы**
**Арча муниципаль районының**
**Арча шәһәре муниципаль берәмлеге**
**Арча шәһәр Советы**
**422000, Арча ш. Совет мәйданы, 27**
**тел. 3-16-25, 3-12-35**

**Арча шәһәр Советы**

**карары**

**« 12 » ноябрь 2015 ел** **№ 11**

**Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы «Алма бакчасы» торак районы территориясен планлаштыру проектын раслау турында**

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 42,45,46 статьялары, "Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" гы 131-ФЗ номерлы федераль закон, Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының «Арча шәһәре» муниципаль берәмлеге Уставы, «Татарстан Республикасы җирләрен дәүләт резервына күчерү турында " Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Башкарма комитетының 2013 елның 6 маендагы 572 номерлы карары нигезендә, Территориянең тотрыклы үсешен тәэмин итү максатларында, территориянең, планлаштыру структурасы элементларын (кварталларны, микрорайоннарны, башка элементларны), капиталь төзелеш объектлары урнашкан җир кишәрлекләре чикләрен, линия объектларын төзү һәм урнаштыру өчен билгеләнгән җир кишәрлекләре чикләрен билгеләү, «Алма бакчасы» торак районы территориясен җентекләп планлаштыру проекты буенча гавами тыңлаулар нәтиҗәләре турында бәяләмә нигезендә Арча шәһәре Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының Арча шәһәрендәге «Алма бакчасы» торак районы территориясен планлаштыру проектын расларга.

2. 7 көн эчендә әлеге карарны Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының «Арча шәһәре» муниципаль берәмлеге Уставында Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында урнаштыру

юлы белән билгеләнгән тәртип нигезендә (http:pravo.tatarstan.ru һәм Арча муниципаль районының рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә (http:/www. arsk.tatarstan.ru) җирлекләр бүлегендә бастырып чыгарырга.

3.Карар рәсми бастырылганнан бирле үз көченә керә.

4.Әлеге карарның үтәлешен " Арча шәһәре» муниципаль берәмлеге башкарма комитеты җитәкчесе Р. Ф. Касыймовка йөкләргә

«Арча шәһәре» муниципаль
берәмлеге башлыгы,
Арча шәһәр Советы рәисе — И.Г. Нуриев